СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.03.2025 г. Агрыз № 45-4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 21.03.2023 елның 27-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендәге күчемле һәм күчемсез мөлкәтне читләштерү турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 22.07.2008 елның 159-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 21.01.2010 елның 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 21.03.2023 елның 27-4 номерлы карары (алга таба - Нигезләмә) белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендәге күчемле һәм күчемсез милекне читләштерү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 6.1 пунктында «биш елга» сүзләрен «сигез елдан артык түгел» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигать ресурслары һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов